# ӨЛГЕРГӘН ШАГЫЙРЬ

Әдәбият мәйданына яшьләр килү, кан, каләм, уй-фикер яңару — күңелле күренеш, татар әдәбиятының киләчәген якты итеп күзаллаганда — искиткеч яхшы фал. Җир йөзендә, табигатьтә, кешелек җәмгыятендә буыннар алмашу туктаусыз бара, бу — закончалык. Әгәр әлеге механизм сүтелә башласа яки бөтенләй тукталып калса, тереклек, яшәеш бетте дигән сүз. Әдәбиятлар, телләр, халыклар белән дә шулай. Гасырлар буена тупланып килгән бай мирасыбызны тапшырырлык, гореф-гадәтләребезне саклырлык һәм дәвам итәрлек, үз чиратында тагын да ераграк меңьеллыкларда дөньяга аваз салачак милләттәшләребезгә васыять итеп калдырырлык яшьләребез калкып чыкмаса, милләтебезнең хәле бик тә аяныч булыр иде.

Аллага шөкер, XXI гасыр башында татар әдәбиятында башланган яңарыш дәвам итә, киң әдәби мәйданга әледәнәле яңа татар шагыйрьләре, татар язучылары аяк баса. Аларга көчле милли үзаң, төпле акыл, тирән хис һәм фәлсәфә, ирлек-хөрлек хас. Инде шагыйрь булып өлгереп җиткән Фәнил Гыйләҗев ерактан ук күзгә ташланып, аерылып тора. Ул — «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә чыныккан егет. Без аның белән берләшмәнең чираттагы бер утырышында таныштык та. Идел-Урал төбәге студентларының «Шигъри Сабантуй» бәйгесендә «Денсезләр авылы» шигырен сөйләп шаккатыруы, «Иделем акчарлагы», «Таян Аллага» конкурсларында Гран-прига лаек булуы, татар юморының өлгесе саналган «Чаян» журналын яулавы, «Шәһри Казан» газетасында эшләве... — болар Фәнилнең әдәбиятка килгән юлы, иҗади үсеш нәтиҗәсе. Хәзер исә аның чираттагы, язмышының хәлиткеч адымы — беренче китабы.

Җыентыкның исеме үк гадәти түгел, күңелне сискәндереп, күз кабакларын баскан йокыдан айнытып җибәрә — «Ризасызлык»... Биредә Ф. Гыйләҗев милли, хисси, юморда шактый гына ат уйнатучы шагыйрь булып ачыла. Аның йөрәгенә оя корган гыйсъянчылык төрле калыпта, төрле юнәлештә, кайчак бертуктаусыз исеп торган җил кебек тәэсир калдыра, кайчак, көчле ташкын булып, йөзгә килеп бәрелә.

Фәнил Гыйләҗев шигъриятенең үзәгендә — бүгенге тормыш, якты да, караңгы да чынбарлык. Ул татар авыллары бетеп баруга, аларның асылы җуелуга чын күңелдән

борчыла. Ә юкка чыгуның сәбәпләре күп: яшьләрнең авылдан китүе, эшсезлек, имансызлык, халыкның эчкечелеккә сабышуы, матур гадәтләрнең югалуы, авыл белән шәһәр арасындагы киртә җуелу…

Ил буенча нигезсезләр үрчи.
Кимеп бара иман.
Авыл бүген гүя иң азаккы
Могиканын җуйган;

Мәктәп ишегендә йозак тора.
…Йозак – авылларның язмышы;

…Эчү ярышлары бара
Авыл Сабан туенда, –

дип яза ул.

Милләтнең шанлы үткәнен белгән хәлдә, халкыбызның бүгенге халәте, торышы да Фәнилне уйландыра. Аның тарихи, сәяси, җәмгыяти әһәмияткә ия вакыйгаларга үз карашы, шигырьләрендә четерекле хәлләрдән чыгу юлларын аңлатырга тырышу да бар. Җавапсыз, кире кагылган мәхәббәт тә шагыйрь күңелендә башта каршылык тудырса, аннан:

Юк, мин сине мәңге оныта алмам!
Ә син оныт! Оныт! Түзәрмен… –

дип, ул егетләрчә сабырлык күрсәтә, кичерешләренең ихласлыгын исбатлый.

Юморына үткен сатира элементлары кертеп, астан гына чеметеп-чеметеп ала.

Ф. Гыйләҗев ахирәт тормышы турында да онытмаска, уйланырга дәшә. Дөнья куып, намаз укуны, ислам дине кануннарын үтәүне кичектермәскә чакыра.

Китап исеме «Ризасызлык» дип аталса да, шагыйрь татар булуы белән горурлана, милләтнең киләчәгендә яктылык, өмет күрә. Аның йоклап каласы килми, шуңа Яңа ел төнендә, сәгать телләре уникене сукканда, ул изге теләк теләп калырга ашыга.

Кыскасы, Фәнилнең үз юлы бар. Ул – татарның шатлык-сөенечләрен, кайгы-хәсрәтләрен җан үзәге аша үткәргән, аларны йөрәгендә йөрткән чын шагыйрь, өлгергән шагыйрь. Киләчәгенең якты, шигъри һәм илһамлы булуын, үзе язганча, утлы каләмен баса-баса иҗат итүен теләп каласы килә!

*Ленар Шәех*



I бүлек

## *Тормыш әле шулай дәвам итә...*

### ИЛҺАМИЯТ

Каләмемне баса-баса яздым,
Яза-яза азау ярганчы:
Дәфтәремнең тәүге бите өчен
Илһами төн булды ла ачы.

Каләмемне басып-басып яздым,
Ярсып-ярсып сыктым карасын...
Шагыйрь булсаң, бәлки,
Бу халәтне
Син үзең дә татып карарсың?!

Җитез каләм җете шаярганда,
Өстәлдәге дәфтәр илерде.
Ак тәненә каләм очларыннан
Шәфәкъ катыш йолдыз сибелде.

...Дәфтәр күкрәгендә кара табы.
Илһами төн узган.
Таң аткан.
Хәлсез ята каләм.
Илһамият
Шагыйрь җанын тырнап канаткан.

## КАСӘ ТӨБЕ

Чишенде дә бетте бар күңелем,
Һәм шәп-шәрә калды бар гамем,
Чишелде тел.
Әллә сихерме бу,
Тәэсиредәй кара каһвәнең?

Күздән йокы качты
Һәм мин... яндым!
Таңга ашкынуым кичекте.
...Касә бушап калгач,
Вөҗүдемә
Җиңел булып калды ничектер.

Касә төбе гөман ишарәсен
Кем бар чынга алып саташкан?!
Һәркем үзе теләгәнен күрер
Адашулы ярты караштан.

## АВЫЛЫМА КАЙТАМ

Авылыма кайтып барам әле:
Урамнарга асфальт түшәлгән;
Кайберәүләр һаман бакчасында,
Чыга алмый йөри түтәлдән.

Олы юлның мосафирын дәшеп,
Мәчет манарасы утлары
Балкып тора эңгер төшкән чакта,
Утлап йөри Фәһим тулпары.

Авыл кырыенда зират. Тынлык.
Агачларны шактый кискәннәр...

Яңа каберлекләр калкып тора,
Дога кылып уза исәннәр.

Кибет арты. Карт буйдаклар йөри
Эшсезлектән, шунда чүмәшеп;
Су буеннан казлар кайтып бара,
Эш майтарган кебек гүләшеп.

Тезелешеп утырыша йортлар:
Кайсы агач аның, кайсы таш,
Кайсы капкаларга йозак элгән,
Кайсы өйдә пешә тәмле аш…

Түбән очтан көтү кайтып килә,
Этләр өрә кайбер йортларда.
Мал башы да шактый сирәгәйгән,
Арткан бушап калган йортлар да…

Авылыма кайтып киләм әле.
Сагындым бит, авылым, сагындым!
Тыкрык саен урый-урый кайтам
Сукмакларын бала чагымның.

## БАЛАЧАК ДУСТЫМА

Икәүләшеп зыян итәр идек,
Икәү бергә качтык Рәҗәбтән…
Һаман вакыйгалар эчендә без,
Гел юлыгып йөрдек мәзәккә…

Булды йомран аулап йөргән вакыт,
Сүткән чаклар карга оясын…
Авыл карчыклары бакчасының
Әрәм булды күпме алмасы…